| | |
|---|---|
| **МИНИСТЕРСТВО СПОРТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫ** |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

07.07.2020 г.Казань №199

Татарстан Республикасы Спорт Министрлыгы боерыгы белән расланган социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына узгәреш керту хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 16 маендагы 395 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары чыгуга бәйле рәвештә

**б о е р а м:**

1. Татарстан Республикасы спорт Министрлыгының 21.02.2020 елның № 78 боерыгы белән расланган Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына, яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә (кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге Боерыкның үтәлешен контрольдә тоту министр урынбасары И.З.Садриевка йөкләргә.

Министр В.А.Леонов

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының 2020 елның 21 февралендәге 78 номерлы боерыгы белән расланды

Социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар күрсәтә торган иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүләрнең сыйфаты билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар күрсәтә торган иҗтимагый яктан файдалы хезмәт күрсәтүләрнең сыйфаты билгеләнгән критерийларга туры килү-килмәве турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – Регламент) социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар күрсәтә торган иҗтимагый яктан файдалы хезмәт күрсәтүләрнең сыйфаты билгеләнгән критерийларга туры килү-килмәве турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте) тәртибен һәм стандартын билгели.

1.2. Гариза бирүчеләр: социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар.

1.3. Дәүләт хезмәтен Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы (алга таба – Министрлык) күрсәтә.

1.3.1. Министрлыкның урнашкан урыны: Казан шәһәре, Петербург урамы, 12 йорт.

Министрлыкның эш тәртибе: шимбә һәм якшәмбедән тыш һәр көнне, 9:00 дан 18:00 кадәр, төшке аш вакыты 12:30 дан 13:30 кадәр.

Гаризалар кабул итү шимбә һәм якшәмбедән тыш һәр көнне Министрлыкның эш сәгатьләрендә тормышка ашырыла.

Җәмәгать транспортында:

- 1, 91, 35а, 37, 29, 90, 71, 47 нче номерлы автобуслар;
- 2, 7, 17, 6, 8, 12 нче номерлы троллейбуслар белән «Божра» тукталышына, метро белән «Тукай мәйданы» станциясенә кадәр килергә.

Рөхсәт кәгазе һәм (яки) шәхесне раслый торган документ буенча узарга мөмкин.

1.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм үтәлеш барышы турында мәгълүмат бирүне 1) югары казанышлар спортын үстерү, 2) массакүләм физкультура-сәламәтләндерү эше бүлекләре, шулай ук: 3) спорт резервын әзерләү, 4) Бөтенроссия «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) физкультура-спорт комплексы чараларын тормышка ашыру буенча, 5) адаптив физкультура һәм студентлар спорты секторлары (алга таба – Бүлек (сектор)) тормышка ашыра.

1.3.3. Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы «Татарстан Республикасы рәсми порталы» дәүләт мәгълүмати системасы составына керә торган рәсми сайты адресы (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты һәм «Интернет» челтәре): http://minsport.tatarstan.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүматны түбәндәге юллар белән алырга мөмкин:

1) Министрлык биналарында урнашкан мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган дәүләт хезмәте турында мәгълүмат стендлары аша;

2) «Интернет» челтәре аша:

Министрлыкның рәсми сайтында (http://minsport.tatarstan.ru/);

Татарстан Республикасы дәүләт һәм һәм муниципаль хезмәтләр порталында: (http://uslugi.tatar.ru);

Дәүләт һәм һәм муниципаль хезмәтләренең (функцияләре) бердәм порталында (https://www.gosuslugi.ru);

3) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать итү ысулы аша (телефон буенча яки шәхсән);

4) Министрлыкка язмача мөрәҗәгать аша (шул исәптән электрон документ рәвешендә).

1.3.5. Министрлык урнашкан урын, белешмә өчен телефоннар, эш графигы, рәсми сайт, шулай ук электрон почта адресы турындагы мәгълүмат Бүлек хезмәткәре тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр реестры» дәүләт мәгълүмати системасында һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр порталында урнаштырыла.

Министрлык биналарында мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган мәгълүмат Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3 - 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларында күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы белешмәләрне үз эченә ала.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә башкарыла:

1995 елның 24 ноябреннән 181-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1995, № 48, 4563 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып)
(алга таба-181-ФЗ номерлы Федераль закон);

1996 елның 12 гыйнвареннән 7-ФЗ номерлы «Коммерциячел булмаган оешмалар турында» Федераль законы (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 1996 ел, № 3, 145 маддә, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба – 7-ФЗ номерлы Федераль закон);

2007 елның 4 декабреннән 329-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» Федераль законы (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2007 ел, № 50, 6242 маддә, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба – 329-ФЗ номерлы Федераль закон);

2010 елның 27 июленнән 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законы (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2010 ел, № 31, 4179 маддә, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алган хәлдә) (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон);

2011 елның 6 апреленнән 63-ФЗ номерлы «Электрон имза турында» Федераль законы (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2011 ел, № 15, 2036 маддә, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алган хәлдә) (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон);

Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маеннан 601 номерлы «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» Указы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2012, 7 май, басылу номеры: 0001201205070016) (алга таба – 601 нче номерлы Указ);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 27 октябреннән 1096 нчы номерлы «Иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү исемлеген һәм аларны күрсәтүнең сыйфатын бәяләү критерийларын раслау турында» карары (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2016 ел, № 45, 6261 маддә, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба – 1096 нчы номерлы Карар);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 26 гыйнвареннән «Коммерциячел булмаган оешмалар – иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүчеләр реестры турында» 89 нчы номерлы карары (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2017 ел, № 6, 937 маддә, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба – 89 нчы номерлы Карар);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 6 июленнән 315 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы турында нигезләмә («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының каарарлары һәм күрсәтмәләре һәм башкарма хакимиятның республика органнары норматив хокукый актлары җыентыгы» журналы, 2005, № 30, 0695 маддә, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алган хәлдә) (алга таба – Нигезләмә);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендә кул куелган 880 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» карары («Татарстан РеспубликасыМинистрлар Кабинетының карарлары һәм күрсәтмәләре һәм башкарма хакимиятның республика органнары норматив хокукый актлары җыентыгы» журналы, 2010, № 46, 2144 маддә, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алган хәлдә) (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 880 номерлы Карары);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 22 августыннан «Татарстан Республикасында социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүләрнең сыйфаты билгеләнгән критерийларга туры килү турында бәяләмәләр бирүне оештыру турында» 681 нче номерлы карары (Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы (pravo.tatarstan.ru, 2018, 31 август) (алга таба – 681 нче номерлы Карар).

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм бәяләмәләр кулланыла:

иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтү – физик культура һәм спорт өлкәсендә физкультура-сәламәтләндерү чараларын оештыру һәм үткәрүгә булышлык итү;

гариза бирүче – дәүләт хезмәте күрсәтү турында телдән, язмача яисә электрон рәвештә сорау белән мөрәҗәгать иткән социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешма (аларның вәкаләтле вәкилләре);

техник хата – Министрлык тарафыннан җибәрелеп, социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүләрнең сыйфаты билгеләнгән критерийларга туры килү турында бәяләмәдә (алга таба – бәяләмә) яисә белдерү кәгазендә күрсәтелгән бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрдә күрсәтелгән мәгълүматларның туры килмәвенә китергән хата (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата);

әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) астында хезмәт күрсәтүне сорап алу аңлашыла («дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 1 пункты (алга таба-210-ФЗ номерлы Федераль закон)

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтә урнашкан эш урыны – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 декабреннән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренең эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 1376 нчы номерлы карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәсенең 34 пунктына туры китереп, Татарстан Республикасы муниципаль районының (шәһәр округының) шәһәр һәм авыл җирлекләрендә булдырылган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең территориаль үзенә аерым структур бүлекчәсе (офисы).

Башка төшенчәләр һәм терминнар 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә кулланыла.

2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтү яки таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте атамасы | Социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүләрнең сыйфаты билгеләнгән критерийларга туры килү турында бәяләмәләр бирү | «Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар күрсәтә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирүне оештыру хакында» 2018 елның 22 августындагы 681 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының (алга таба – 2018 елның 22 августындагы 681 номерлы ТР МКК 2 пункты) |
| 2.2. Башкарма хакимият органы атамасы | Татарстан Республикасы Спорт Министрлыгы | 89 нче номерлы Карар белән расланган Иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүләрне |

| | | |
|---|---|---|
| | | башкаручы социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешма итеп тану турында карар кабул итү кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр)<br>2018 елның 22 августындагы 681 номерлы ТР МКК 2 пункты |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен сурәтләү | Кагыйдәләрнең 2 нче кушымтасындагы форма буенча бәяләмә яисә әлеге Регламентның 3 нче кушымтасы буенча бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерү кәгазе | Кагыйдәләрнең 5,7,8 нче пунктлары |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәклеген истә тотып; әгәр Россия Федерациясе Законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган булса, дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (юллау) вакыты | Бәяләмә бирү турында гариза кергән көннән алып 30 көн эчендә.<br>Күрсәтелгән вакыт, Кагыйдәләрнең 6 нчы пункты буенча Министрлык тарафыннан сораулар юлланган очракта, озайтылырга мөмкин, әмма 30 көннән дә артык вакытка түгел.<br>Күрсәтелгән карарны кабул итү вакытын озынайту турында Министрлык гариза бирүчегә ул кызыксынган органга оешманың бәяләмә бирү турында гаризасы кергән көннән соң 30 көн эчендә хәбәр итә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору Россия Федерациясе законнарында каралмаган.<br>Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документны бирү гариза бирүче мөрәҗәгате көнендә гамәлгә ашырыла. | Кагыйдәләрнең 6, 9 нчы пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| | Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документны гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып (почта аша, электрон адрес, факс буенча) дәүләт хезмәте нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә җибәрелә | |
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен законнар һәм башка норматив хокукый актларда каралган, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарур һәм мәҗбүри булган хезмәтләр өчен Гариза бирүче тәкъдим итәргә тиешле мәҗбүри документларның тулы исемлеге, гариза бирүче тарафыннан, шул исәптән электрон формада да, аларны алу ысуллары | а) әлеге Регламентның 1 нче кушымтасындагы форма буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза);<br>б) оештыру документларының күчермәләре;<br>в) документларны гариза бирүченең вәкиле тапшырган очракта, гариза бирүче исеменнән эш итү өчен кирәк булган гариза бирүченең вәкиле вәкаләтләрен раслаучы ышаныч кәгазе.<br>Гариза почта аша заказлы хат белән җибәрелергә мөмкин. .<br>Гариза бирүче оешма күрсәтә торган хезмәтнең иҗтимагый яктан файдалы хезмәт күрсәтү сыйфатында куелган критерийларга туры килүен нигезли торган документларны (белешмәләр, сыйфатламалар, эксперт бәяләмәләре, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары каршындагы иҗтимагый советлар бәяләмәләре һәм башкалар) теркәргә мөмкин.<br>Әгәр гариза бирүче тиешле иҗтимагый файдалы хезмәт буенча социаль хезмәт күрсәтүчеләр реестрына керә икән, гариза бирүче күрсәтә торган хезмәтләрнең иҗтимагый яктан файдалы хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын билгеләнгән критерийлар буенча бәяләүгә туры килүен нигезли торган өстәмә документлар бирү таләп ителми. | Кагыйдәләрнең 5 нче пункты |

| | | |
|---|---|---|
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәк булган һәм Гариза бирүче бирергә хокуклы булган документларының тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүчеләрнең аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә дә, аларны бирү тәртибе; әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | Россия Федерациясенең салымнар һәм җыюлар турында законнары буенча түләргә тиешле салымнар, җыюлар, иминият кертемнәре, пеня, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмавын, оешманың гариза бирүче документлар тапшыра торган айның 1 нче көненә намуссыз тәэминәтчеләр (подрядчылар, башкаручылар) исемлегендә булмавын раслый торган документлар.<br>Гариза бирүченең югарыда күрсәтелгән мәгълүматларны үз эченә алган документларны бирмәве гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга нигез булып тормый.<br>Гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела: дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яисә тормышка ашыру каралмаган гамәлләрне тормышка ашыру яисә документлар һәм мәгълүмат тапшыру;<br>210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 нче маддәсенең 6 нчы өлешендә каралган документлардан тыш, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтә торган дәүләт органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яки) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмалар карамагында булган, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен гариза бирүче керткән түләүне раслый торган документлар һәм мәгълүматны бирү;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе кагыйдәләренең 6 пункты (алга таба-02.11.2010 елның № 880 ТР МК |

| | | |
|---|---|---|
| | документларны кабул итүдән яисә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 нче маддәсенең 1 нче өлеше 4 нче пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренчел баш тарту вакытында аларның булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүматлар бирү | тарафыннан расланган тәртип) |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мәҗбүри булган документларны кабул итүдән баш тарту өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге | Гариза бирүче яисә аның вәкиле тарафыннан Регламентның 2.5 пунктында саналган документлар бирелмәгән. | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә аңардан баш тарту өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге | Бәяләмә бирүдән баш тарту өчен сәбәп булып түбәндәгеләр тора:<br>а) иҗтимагый файдалы хезмәтнең аның эчтәлегенә (хезмәт күрсәтүнең күләме, вакытлары һәм сыйфаты) Россия Федерациясе норматив-хокукый актлары билгеләгән таләпләргә туры килмәве;<br>б) иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүдә турыдан-туры җәлеп ителгән затларның кирәкле квалификациясе булмау; квалификациясе булган затлар санының җитәрлек булмавы; | Кагыйдәләрнең 7 нче пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | в) бәяләмә бирер алдыннан ике ел эчендә суд, дәүләт тикшерүе (күзәтчелеге) һәм муниципаль күзәтчелек органнары, башка дәүләт органнарының аның компетенциясенә туры килүенең нигезләнгән булып танылган гамәлләренә (гамьсезлекләренә) һәм (яки) иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтү белән аңа бәйле оешма карарына шикаять булуы;<br>г) оешма турында мәгълүматның ачык һәм аңлаешлы булу дәрәҗәсенең Россия Федерациясе норматив-хокукый актлары белән билгеләнгән таләпләргә (алар булганда) туры килмәве;<br>д) бәяләмә бирер алдыннан ике ел эчендә оешма турында 2013 елның 5 апреленнән 44-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хаҗәтләр өчен товарлар, хезмәтләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль законы буенча төзелгән контрактларны үтәү кысаларында хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча намуссыз тәэминатчылар реестрында мәгълүмат булуы;<br>е) салымнар һәм җыемнар, Россия Федерациясе законнарында каралган башка төр мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булу;<br>ж) дөрес түгел мәгълүматлары булган документлар яисә тиешле тәртиптә рәсмиләштерелмәгән документлар бирү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен сәбәпләр юк. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка төр түләүнең тәртибе, күләме | Дәүләт хезмәте бушлай күрсәтелә. | |

| | | |
|---|---|---|
| һәм алу өчен сәбәп | | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләр, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмалар бирә торган документ (документлар) турында белешмәләр исемлеге | Зарури һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтүләр таләп ителми | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасының, шундый төр түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп, түләүнең тәртибе, күләме һәм алу өчен сәбәпләр | Зарури һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтүләр таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма бирә торган хезмәт күрсәтү турында запрос биргән вакытта һәм шундый хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты | Дәүләт хезмәте алучының (гариза бирүченең) кабул итүне (хезмәт күрсәтүне) көтүнең һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алуның максималь вакыты 15 минуттан да артмаска тиеш.<br>Дәүләт хезмәте алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. | 601 нче номерлы Указның 1 нче пункты «д» подпункты |

| | | |
|---|---|---|
| 2.13. Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтүне һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма күрсәтә торган хезмәт күрсәтүне, шул исәптән электрон формада да, сорап язган гаризаны теркәү вакыты һәм тәртибе | Гариза кергән көндә.<br>Гариза электрон формада ял (бәйрәм) көнендә кергән очракта – ял (бәйрәм) көненнән соңгы эш көнендә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтүне сорауларны тутыру урыннарына, аларны тутыру үрнәкләре һәм һәрбер дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәк булган документлар исемлеге белән мәгълүмати стендларга, шундый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүматны урнаштыру һәм бизәүгә карата, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуларын тәэмин итүгә карата | Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәк булган мебель, мәгълүмати стендлар белән җиһазланган биналарда һәм бүлмәләрдә башкарыла.<br>Инвалидларның дәүләт хезмәте күрсәтү урынына комачаулыкларсыз килүе, шул исәптән объектларга комачаулыкларсыз керү һәм аннан чыгу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү урынына килү максатларында объект буенча мөстәкыйль күчеп йөрү мөмкинлеге тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиялы мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла. | «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон; 02.11.2010 елның № 880 ТР МК тарафыннан расланган тәртип |

| | | |
|---|---|---|
| таләпләр | | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең файдалана алырлык булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгән вакытта вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнеше һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында, шул исәптән мәгълүмати-телекоммуникацион технологияләрне дә файдаланып, яисә 210-ФЗ номерлы Федераль законның $15^1$маддәсендә каралган дәүләт һәм муницпаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә берничә дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүне сорау юлы белән дәүләт хезмәтен дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфукцияле үзәкләрендә, гариза бирүче теләге буенча башкарма хакимиятнең теләсә кайсы территориаль бүлекчәсендә (экстерриториаль принцип) алу- | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең файдалана алырлык булуы күрсәткечләре булып торалар:<br>биналарның җәмәгать транспортыннан файдалана алырлык зонада урнашуы;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуы;<br>белгечләрнең, шулай ук гариза бирүчеләрдән документларны кабул итә торган бүлмәләрнең кирәкле санда булуы;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакыты турында мәгълүмати стендларда, «Интернет» челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләр) бердәм порталында тулы мәгълүмат булуы;<br>гаризаны электрон формада бирү мөмкинлеге;<br>гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен электрон рәвештә алу мөмкинлеге;<br>инвалидларга биналарның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуы белән бәйле булмаган калган затлар белән бертигез хезмәт күрсәтүләр алуга комачаулык итә торган башка барьерларны җиңәргә ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфаты күрсәткечләре булып торалар:<br>документларны кабул итү һәм карау вакытларын саклау;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен алу вакытын саклау;<br>Министрлык белгечләре тарафыннан җибәрелгән әлеге Регламентны бозуга карата прецедентлар (нигезле | |

| | | |
|---|---|---|
| алмау мөмкинлеге (шул исәптән тулы күләмдә) | шикаятьләр) булмау.<br>Гариза бирүченең Министрлык белгечләре белән үзара тәэсир итешү саны:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документларны биргән вакытта – бердән артмаска тиеш (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документларны почта аша юллаганда – булмый (консультацияләрне исәпкә алмыйча).<br>Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүченең Министрлык белгече белән бер үзара тәэсир итешүенең дәвамлылыгы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүне дә кертеп, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге, күпфункцияле үзәгенең ерактагы эш урыннары аша тормышка ашырылмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүматны гариза бирүче http://minsport.tatarstan.ru сайтында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләр) бердәм сайтында ала ала.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү экстерриториаль принцип һәм комплекслы сорау буенча гамәлгә ашырылмый. | |
| 2.16. Башка таләпләр, шул исәптән дәүләт хезмәтен экстерриториаль принцип буенча күрсәтүнең (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән | Гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) Министрлыкка «электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган (расланган) электрон документлар рәвешендә | 63-ФЗ номерлы Федераль закон<br>210-ФЗ номерлы Федераль закон |

| | | |
|---|---|---|
| очракта) үзенчәлекләрен исәпкә алып, һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре. | юлланылырга мөмкин. | |

## 3. Административ процедураларның (гамәллэрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәү вакыты, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон формадагы административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәткән вакытта гамәлләр эзлеклелеген сурәтләү

3.1.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү һәм ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәк булган документларны рәсмиләштерүдә ярдәм күрсәтү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) гариза бирү вакытында җибәрелгән бозуларны юкка чыгару;

4) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга ведомствоара запрослар формалаштыру һәм юллау;

5) бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерү кәгазе проектын әзерләү;

6) гариза бирүчегә бәяләмәне яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерү кәгазен бирү;

7) техник хатаны төзәтү.

3.2. Гариза язучыга консультация бирү, гариза бирүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәк булган документларны тутыру өлешендә ярдәм күрсәтү.

Гариза бирүче Бүлеккә шәхсән, телефон аша һәм (яки) почта ярдәмендә (шул исәптән электрон) дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультация алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече гариза бирүчегә, шул исәптән сорау (запрос) формасы һәм дәүләт хезмәтен алу өчен кирәк булган башка мәсьәләләр буенча консультация үткәрә. Кирәк булган очракта Бүлек белгече гариза бирүчегә, шул исәпән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәк булган документларны тутыру өлешендә ярдәм күрсәтә.

Әлеге пункт белән билгеләнеп куела торган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: консультация, бирелгән документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча күрсәтмәләр, гариза бирүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документларны тутыру өлешендә ярдәм күрсәтү, гражданнар мөрәҗәгатьләрен теркәү журналына консультация бирү (гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү) турында язма.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Гариза бирүче Министрлыкның оештыру эше, эш башкару һәм тикшерү бүлегенә (алга таба – Оештыру бүлеге) гаризаны шәхсән бирә.

Гариза почта аша заказлы хат белән җибәрелергә мөмкин.

Электрон формада юллана торган гариза 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон буенча имзалана (раслана) һәм электрон мәгълүмат тапшыргычлар һәм (яки) гомуми кулланыштагы мәгълүмати-телекоммуникация челтәрләрен, «Интернет» челтәрен дә кертеп, кулланып тәкъдим ителә.

Гариза шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре

порталы аша да бирелергә мөмкин.

Почта аша заказлы хат белән яки электрон формада җибәрелгән гариза гомуми тәртиптә карала.

3.3.2. Оештыру бүлеге белгече:

дәүләт хезмәте алучының вәкаләтле заты яисә законлы вәкиле буларак гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерә;

әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның барлыгын һәм аларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерүне тормышка ашыра. Тикшерү Бүлек белгече катнашында тормышка ашырыла.

Гариза бирүче шәхсән мөрәҗәгать иткәндә әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тарту өчен сәбәпләр булган очракта, белгеч гариза бирүчегә документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту өчен сәбәпләр булуын хәбәр итә һәм аңа, баш тарту өчен ачыкланган сәбәпләрнең эчтәлеген аңлатып, документларны кире кайтара. Гариза бирүче таләбе буенча баш тарту язмача рәвештә рәсмиләштерелә.

Гариза бирүче гаризаны һәм документларны почта (электрон почта) аша юллаган вакытта Оештыру бүлеге белгече аңа, баш тарту өчен ачыкланган сәбәпләрнең эчтәлеген аңлатып, документларны почта (электрон почта) аша кире кайтара.

Документларны кабул итеп алудан баш тарту өчен сәбәпләр булмаган очракта Оештыру бүлеге белгече түбәндәге гамәлләрне башкара:

гаризаны кабул итә һәм терки;

документларны кабул итү көнен, вакытын, керү номерын күрсәтеп, гариза күчермәсен тапшыра яки почта яисә электрон почта аша (аның теләге буенча) җибәрә;

гаризаны электрон формада Татарстан Республикасы спорт министрына (алга таба – министр) «Электрон Хөкүмәт» Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең электрон документ әйләнешенең ведомствоара системасы (алга таба – электрон документ әйләнеше) аша юллый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза кергән көнне үк тормышка ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм министрга юлланган гариза.

3.3.3. Министр гаризаны карый һәм карау өчен министрның беренче урынбасарына юллый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән көнне тормышка ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: министрның беренче урынбасарына карауга юлланган гариза.

3.3.4. Министрның беренче урынбасары гаризаны карый һәм карау өчен Бүлек башлыгына юллый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән көнне тормышка ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына карауга юлланган гариза.

3.3.5. Бүлек башлыгы җаваплы башкаручыны (алга таба – Бүлек белгече) билгели һәм гаризаны үтәү өчен аңа тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән көннән бер эш көне эчендә тормышка ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: үтәү өчен Бүлек белгеченә юлланган гариза.

3.4. Бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерү кәгазе бирү турында карар әзерләү һәм кабул итү.

3.4.1. Бүлек белгече:

гаризаны карый;

гариза бирүче Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны бирмәгәндә, әлеге Регламентның 3.5 пунктында каралган гамәлләр башкарыла.

бергә теркәп җибәрелә торган хатның, бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерү кәгазенең проектын әзерли һәм килештерү өчен Бүлек башлыгына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны үтәү өчен Бүлек белгеченә юлланган көннән ундүрт көн эчендә, әмма әлеге Регламентта билгеләнгән бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерү кәгазе бирү вакыты бетүгә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча тормышка ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: килештерү өчен Бүлек башлыгына җибәрелгән бергә теркәп җибәрелә торган хатның, бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерү кәгазенең проектлары.

3.4.2. Бүлек башлыгы бергә теркәп җибәрелә торган хатның, бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерү кәгазенең проектларын тикшерә һәм килештерү өчен аларны министрның беренче урынбасарына юллый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура күрсәтелгән проектларның килештерү өчен Бүлек башлыгына кергән көнне тормышка ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: министрның беренче урынбасарына килештерүгә юлланган бергә теркәп җибәрелә торган хатның, бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерү кәгазенең проектлары.

3.4.3. Министрның беренче урынбасары бергә теркәп җибәрелә торган хатның, бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерү кәгазенең проектларын килештерә һәм министрга юллый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура күрсәтелгән проектларның килештерү өчен кергән көнендә тормышка ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерелгән һәм министрга карауга юлланган бергә теркәп җибәрелә торган хатның, бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерү кәгазенең проектлары.

3.4.4. Министр бергә теркәп җибәрелә торган хатны имзалый, бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерү кәгазенең проектын килештерә.

Имзаланган бергә теркәп җибәрелә торган хат, килештерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерү кәгазе Оештыру бүлегенә юллана.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура күрсәтелгән проектларның килештерү өчен министрга кергән көнендә тормышка ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Оештыру бүлегенә теркәүгә юлланган министр тарафыннан имзаланган бергә теркәп җибәрелә торган хат, килештерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерү кәгазе проектлары.

3.4.5. Бүлек белгече:

бергә теркәп җибәрелә торган хатны терки һәм бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерү кәгазенең проекты белән бергә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына юллый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар министр тарафыннан теркәп җибәрелә торган хатны имзаланган, бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерү кәгазенең проектын килештергән көнне тормышка ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имза кую өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына юлланган бергә теркәп җибәрелә торган хат, килештерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерү кәгазе проекты.

3.4.6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан Татарстан Республикасы Премьер-министрының социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар белән үзара хезмәттәшлек мәсьәләләре белән җитәкчелек итә торган урынбасары имзалаган бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерү кәгазен алганнан соң, Бүлек белгече бергә теркәп җибәрелә торган хат проектын әзерли, аны бүлек башлыгы, Татарстан Республикасы спорт министрының беренче урынбасары белән килештерә һәм министрга имзага юллый. Министр бергә теркәп җибәрелә торган хатны имзалый һәм аны Бүлеккә юллый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан Татарстан Республикасы Премьер-министрының социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар белән үзара хезмәттәшлек мәсьәләләре белән җитәкчелек итә торган урынбасары имзалаган бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерү кәгазен алганнан соң бер эш көне эчендә тормышка ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлеккә юлланган министр имзалаган бергә теркәп җибәрелә торган хат.

3.4.7. Бүлек белгече:

гариза бирүчегә, гаризасында күрсәтелгән ысулны кулланып, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе турында хәбәр итә, бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерү кәгазе белән  бергә теркәп җибәрелә торган хатны теркәү өчен Оештыру бүлегенә тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар теркәп җибәрелә торган хат министр тарафыннан имзаланган көнне тормышка ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Оештыру бүлегенә теркәүгә тапшырылган бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерү кәгазе белән  бергә теркәп җибәрелә торган хат.

3.5. Ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы (алга таба – ВЭХС) аша дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар булган органнарга ведомствоара запросларны формалаштыру һәм җибәрү.

3.5.1. Бүлек белгече Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенә ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә электрон формада Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан (ЕГРЮЛ) мәгълүматлар бирү турында сораулар җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мәгълүмат бирү турында сорау.

3.5.2. Ведомствоара хезмәттәшлек органы белгечләре ведомствоара электрон багланышлар хезмәттәшлек системасы аша кергән сораулар нигезендә билгеләнгән срокта соратып алына торган документларны (белешмәләрне) җибәрәләр.

Процедураларның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында юлланган сораулар, сорауларга җавап бирү нәтиҗәсе булып торган белешмәләр (документлар) яки соратып алына торган белешмәләрне бирүдән баш тарту турында белдерү.

3.6. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен юллау.

3.6.1. Бүлек белгече:

бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы дәлилләнгән аңлатма кәгазе белән бергә җибәрелә торган хатны терки һәм гариза бирүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән юллый (тапшыра).

Әлеге пункт белән билгеләнелә торган процедуралар бергә беркетелгән хатка министр тарафыннан кул куелган көнне тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: теркәлгән һәм гариза бирүчегә юлланган (тапшырылган) бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы дәлилләнгән аңлатма кәгазе белән бергә җибәрелә торган хат.

3.7. Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталының Интернет-кабул итү бүлмәсе аша кергән гаризаны карау.

Интернет-кабул итү бүлмәсе аша кергән гариза әлеге Регламентның 3.3-3.5 пунктларында каралган тәртиптә теркәлә һәм карала.

3.8. Техник хатаны төзәтү.

Бәяләмәне яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы аңлатма кәгазен яңадан рәсмиләштерү элегрәк бирелгән бәяләмәдә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы аңлатма кәгазендә җибәрелгән техник хатаны (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата) юкка чыгару белән бәйле рәвештә тормышка ашырыла.

Бәяләмәне яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы аңлатма кәгазен яңадан рәсмиләштерү ирекле формада төзелгән әлеге Регламентның 3.3.1 пунктында күрсәтелгән ысулларның берсе ярдәмендә бирелгән һәм теркәлгән мөрәҗәгать (алга таба – мөрәҗәгать) нигезендә тормышка ашырыла. Мөрәҗәгатькә гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән, әмма техник хата җибәрелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы аңлатма кәгазе, шулай ук, документлар гариза бирүченең вәкиле тарафыннан бирелгән очракта, гариза бирүче исеменнән гамәлләр башкаруны тормышка ашыру өчен кирәк булган вәкаләтләрне раслый торган ышаныч кәгазе теркәлә.

3.8.1. Оештыру бүлеге белгече түбәндәге эшләрне башкара:

техник хатаны төзәтү турындагы мөрәҗәгатьне кабул итә һәм электрон документ әйләнешендә терки;

мөрәҗәгатьне электрон документ әйләнеше аша электрон формада министрга юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнелә торган процедура мөрәҗәгать кергән көнне тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм министрга юлланган мөрәҗәгать.

3.8.2. Министр мөрәҗәгатьне карый һәм һәм карап чыгу өчен министрның беренче урынбасарына юллый.

Әлеге пунктта билгеләнелә торган процедура мөрәҗәгать теркәлгән көнне тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: карап чыгу өчен министрның беренче урынбасарына юлланган мөрәҗәгать.

3.8.3. Министрның беренче урынбасары мөрәҗәгатьне карый һәм карап чыгу өчен Бүлек башлыгына юллый.

Әлеге пунктта билгеләнелә торган процедура мөрәҗәгать теркәлгән көнне тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: карап чыгу өчен Бүлек башлыгына юлланган мөрәҗәгать.

3.8.4. Бүлек башлыгы Бүлек белгечен билгели һәм башкару өчен мөрәҗәгатьне аңа тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнелә торган процедура мөрәҗәгатьне Бүлеккә юллаган көннән соң бер эш көне дәвамында тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: башкару өчен Бүлек белгеченә юлланган мөрәҗәгать.

3.8.5. Бүлек белгече:

бергә беркетелә торган хатны, яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы аңлатма язуы проектын әзерли;

бергә беркетелә торган хатны, яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы аңлатма язуы проектын килештерү өчен Бүлек башлыгына юллый.

Әлеге пунктта билгеләнелә торган процедуралар башкару өчен мөрәҗәгатьне Бүлек белгеченә юллаган көннән алып бер эш көне дәвамында тормышка ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: килештерү өчен Бүлек башлыгына юлланган бергә беркетелә торган хат, яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы аңлатма язуы проекты.

3.8.6. Бүлек башлыгы әзерләнгән бергә беркетелә торган хатның, яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы аңлатма язуы проектының дөреслеген тикшерә, аны килештерә һәм килештерү өчен министрның беренче урынбасарына юллый.

Әлеге пунктта билгеләнелә торган процедура килештерү өчен бергә беркетелә торган хат, яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы дәлилләнгән аңлатма язуы проекты Бүлек белгеченнән кергән көндә тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек башлыгы белән килештерелгән һәм килештерү өчен министрның беренче урынбасарына юлланган бергә беркетелә торган хат, яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы дәлилләнгән аңлатма язуы проекты.

3.8.7. Министрның беренче урынбасары бергә беркетелә торган хатны, яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән дәлилләнгән баш тарту турындагы дәлилләнгән аңлатма язуы проектын килештерә һәм аларны министрга юллый.

Әлеге пунктта билгеләнелә торган процедура Бүлек башлыгыннан бергә беркетелә торган хат, яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы дәлилләнгән аңлатма язуы проекты кергән көндә тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: министрның беренче урынбасары белән килештерелгән һәм карау өчен министрга юлланган бергә беркетелә торган хат, яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы дәлилләнгән аңлатма язуы проектлары.

3.8.8. Министр бергә беркетелә торган хатны имзалый, килештерелгән яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы дәлилләнгән аңлатма язуы проектын килештерә.

Имзаланган бергә беркетелә торган хат, килештерелгән яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы дәлилләнгән аңлатма язуы проекты Оештыру бүлегенә юллана.

Әлеге пунктта билгеләнелә торган процедура күрсәтелгән проектларның министрга килештерүгә кергән көнендә тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Оештыру бүлегенә теркәү өчен тапшырылган министр тарафыннан имзаланган бергә беркетелә торган хат, яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмәнең яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы дәлилләнгән аңлатма язуының килештерелгән проекты.

3.8.9. Оештыру бүлеге белгече:

бергә беркетелә торган хатны терки һәм яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы дәлилләнгән аңлатма язуы проекты белән бергә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына юллый.

Әлеге пунктта билгеләнелә торган процедуралар министр тарафыннан бергә беркетелә торган хатны имзалаган һәм яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы аңлатма язуы проектын килештерелгән көндә тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: имза кую өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына юлланган бергә беркетелә торган хат, килештерелгән яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы дәлилләнгән аңлатма язуы проекты.

3.8.10. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан Премьер-министрның социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар белән үзара хезмәттәшлек мәсьәләләре белән җитәкчелек итә торган урынбасары имзалаган яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы аңлатма язуы проектын алганнан соң, Бүлек белгече бергә беркетелә торган хат проектын әзерли, аны бүлек башлыгы, министрның беренче урынбасары белән килештерә һәм имза кую өчен министрга юллый. Министр бергә беркетелә торган хатны имзалый һәм аны Бүлеккә юллый.

Әлеге пунктта билгеләнелә торган процедуралар Премьер-министрның социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар белән үзара хезмәттәшлек мәсьәләләре белән җитәкчелек итә торган урынбасары имзалаган яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы дәлилләнгән аңлатма язуы проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан алган көннән соң бер эш көне дәвамында тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: министр имзалаган, Бүлеккә юлланган бергә беркетелә торган хат.

3.8.11. Бүлек белгече:

гариза бирүчегә документның әзерлеге турында техник хатаны төзәтү турында мөрәҗәгатьтә яки дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризада күрсәтелгән элемтә ысулы белән хәбәр бирә, Оештыру бүлегенә теркәү өчен яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы дәлилләнгән аңлатма язуы белән бергә беркетелә торган хатны тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнелә торган процедуралар министр тарафыннан бергә беркетелә торган хат имзаланган көндә тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Оештыру бүлегенә теркәүгә тапшырылган яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы дәлилләнгән аңлатма язуы белән бергә беркетелә торган хат.

3.8.12. Оештыру бүлеге белгече:

яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы дәлилләнгән аңлатма язуы белән бергә беркетелә торган хатны терки һәм мөрәҗәгатьтә яисә гаризада күрсәтелгән ысул белән аны гариза бирүчегә тапшыра (юллый).

Әлеге пунктта билгеләнелә торган процедуралар министр тарафыннан бергә беркетелә торган хат имзаланган көндә тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: теркәлгән, гариза бирүчегә тапшырылган (юлланган) яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы дәлилләнгән аңлатма язуы белән бергә беркетелә торган хат.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерү тәртибе һәм формалары

4.1. Министрлыкның җаваплы вазыйфаи затлары тарафыннан Регламент нигезләмәләрен һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә карата таләпләрне билгели торган башка төр норматив хокукый актларны саклауны һәм үтәүне, шулай ук җаваплы затлар тарафыннан карарлар кабул итүне агымдагы тикшерү тиешле административ процедураның үтәлеше өчен җаваплы зат һәм министрның дәүләт хезмәте күрсәтү буенча эш оештыру өчен җаваплы урынбасары тарафыннан тормышка ашырыла.

4.2. Агымдагы тикшерү Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан регламент нигезләмәләрен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләрне билгели торган башка норматив хокукый актларны саклау һәм үтәүне тикшерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы тикшерү даими нигездә башкарыла.

4.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшерү үз эченә тикшерүләр уздыру, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамьсезлекләренә) шикаять булган мөрәҗәгатьләрне карау, карар кабул итү һәм җавап әзерләүне ала.

Административ процедураларны үтәүне тикшерү формалары булып түбәндәге тикшерүләр үткәрү тора:

эш башкаруны алып баруны;

документларны карау нәтиҗәләренең законнар (әлеге Регламент) таләпләренә туры килүен;

документларны кабул итү вакытларын һәм тәртибен саклауны;

дәүләт хезмәтен күрсәткән чакта нәтиҗәләрне бирү вакытларын һәм тәртибен үтәүне.

Тикшерүләр үткәрүнең кабатланып торуы планлы (эш планы нигезендә уздырыла) һәм планнан тыш (гариза бирүченең аерым мөрәҗәгате буенча) характерда була.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын планнан тыш тикшерү үткәрү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) элегрәк ачыкланган Регламент таләпләрен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләрне билгели торган башка норматив хокукый актларны бозуларны бетерүне тикшерү белән бәйле рәвештә;

2) Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган вазыйфаи затларының гамәлләренең (гамәл кылмауларының) аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга карата шикаятьләре белән юридик затларның мөрәҗәгатьләре.

4.5. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокукларын бозган очракларны ачыклаган вакытта гаепле дип танылган дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.6. 4.3. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерү дәүләт хезмәте күрсәткәндә Министрлык эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләр (шикаятьләр) карауның судка кадәр карау мөмкинлеге турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат бирү юлы белән тормышка ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, эшчеләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамьсезлегенә) судка кадәр (судтан тыш) дәгъва бирүтәртибе

5.1. Гариза бирүчеләрнең Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи затының яисә Министрлыкның дәүләт хезмәткәренең гамәлләренә (гамьсезлегенә) карата судка кадәр тәртиптә – Министрлыкка дәгъва бирү хокукы бар. Министр тарафыннан кабул ителгән дәүләт хезмәте күрсәтү белән бәйле карарларга һәм гамәлләргә (гамьсезлекләр) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә.

5.2. Гариза бирүче шул исәптән түбәндәге очракларда да шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны (запрос) теркәү вакытын бозган очракта;

2) дәүләт хезмәте күрсәтүнең вакытын бозганда;

3) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган яки тормышка ашырылмаган документлар яки мәгълүматлар таләп иткәндә яисә гамәлләрне тормышка ашырганда;

4) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында

каралган документларны кабул итүне кире каккан чакта;

5) әгәр кире кагу өчен сәбәпләр федераль законнар, аларга бәйле кабул ителгән башка Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүне кире какканда;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү кертүне таләп иткән очракта;

7) Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталар яисә хәреф хаталарын төзәтүдән баш тарткан яисә шундый төзәтүләрнең билгеләнгән вакытын бозган чагында;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү тәртибен яки вакытын бозган очракта;

9) туктату өчен сәбәпләр федераль законнар, аларга бәйле кабул ителгән башка Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору;

10) дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 нче маддәсенең 1 нче өлеше 4 нче пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул иткәндә беренчел кире кагу вакытында аларның булмавы һәм (яисә) дөрес түгеллеге күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүмат таләп итү.

5.3. Шикаять язмача рәвештә кәгазьдә яки электрон формада бирелә.

Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты, Министрлыкның дәүләт хезмәткәренең, министрның карарларына һәм гамәлләренә (гамьсезлегенә) шикаять почта аша, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәге аша, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайты, Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталы, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләренең (функцияләре) бердәм порталы аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчедән шәхси кабул итү вакытында кабул итеп алынырга мөмкин.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

1) карарлары яисә гамәлләренә (гамьсезлегенә) карата шикаять бирелә торган Министрлык атамасы, Министрлыкның вазыйфаи заты яисә дәүләт гражданлык хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүче – физик затның исеме, фамилиясе, атасының исеме (булган очракта), тору урыны турында белешмә, гариза бирүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта (булган очракта) адресы (адреслары) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиеш булган почта адресы;

3) Министрлык, аның вазыйфаи заты яки дәүләт хезмәткәренең дәгъвалана торган карарлары һәм гамәлләре (гамьсезлеге) турында мәгълүмат;

4) гариза бирүче Министрлык, аның вазыйфаи заты яисә дәүләт гражданлык хезмәткәренең карары һәм гамәлләре (гамьсезлеге) белән килешмәгән дәлилләр. Гариза бирүче тарафыннан гариза бирүченең дәлилләрен раслый торган

документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тәкъдим ителергә мөмкин.

5.5. Гариза бирүче үзенең дәлилләрен раслый документларны (булган очракта), яисә аларның күчермәләрен бирә ала.

5.6. Шикаятьне карау вакыты – аны теркәгән көннән башлап 15 эш көне дәвамында. Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты тарафыннан гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яки җибәрелгән язудагы һәм басмадагы хаталарны төзәтүдән баш тартуга карата шикаять белдергән очракта яисә мондый төр төзәтүләрнең билгеләнгән вакытын бозуга шикаять язган очракта – аны теркәгән көннән алып биш эш көне дәвамында.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәсе буларак түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда язуда һәм басмада җибәрелгән хаталарны төзәтү, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән алу каралмаган акчалата чараларны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соңгы көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язмача яисә гариза бирүченең теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезле җавап юллана.

5.8. Шикаятьне канәгатьләндерерлек дип таныган очракта, гариза бирүчегә адресланган җавапта дәүләт хезмәтен күрсәткән чакта ачыкланган бозуларны кичекмәстән юкка чыгару максатында Министрлык тарафыннан тормышка ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлык өчен гафу үтенелә һәм алга таба дәүләт хезмәтен алу максатында гариза бирүчегә башкарырга кирәк булган эш-гамәлләр турында мәгълүмат бирелә.

5.9. Шикаятьне канәгатьләндерерлек түгел дип тапкан очракта, гариза бирүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләрен күрсәтеп нигезле аңлатма, шулай ук әлеге карарга карата шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.10. Шикаятьне карау дәвамында яки нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яисә җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау буенча вәкаләт бирелгән вазыйфаи зат булган барлык материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына юллый.

Социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар күрсәтә орган иҗтимагый яктан файдалы хезмәт күрсәтүләрнең сыйфаты билгеләнгән критерийларга туры килү-килмәве турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта
(тәкъдим ителә торган форма)

Татарстан Республикасы
спорт министрына
________________________________
(фамилия, инициаллар)
________________________________
________________________________
(оешма атамасы, адрес
(почта һәм (я) электрон),
телефон номеры (булган очракта)

ГАРИЗА

Сездән социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешма ________________
________________________________________________________________________
(социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешма атамасы)
тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый яктан файдалы хезмәт күрсәтүнең сыйфаты _____________________________________________________________
(иҗтимагый яктан файдалы хезмәт атамасы)
аларны тәкъдим итү тармагында билгеләнгән критерийларга туры килү турында бәяләмә бирүегезне сорыйм.

Оешма чит ил агенты функцияләрен башкара торган коммерциячел булмаган оешма булмавын һәм бер ел һәм аннан да артыграк вакыт эчендә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 27 октябрендә кабул ителгән «Иҗтимагый яктан файдалы хезмәтләр исемлеген һәм аларны күрсәтү сыйфатын бәяләү критерийларын раслау турындагы» карары белән расланган иҗтимагый яктан файдалы хезмәтләрне күрсәтү сыйфатын бәяләү критерийларына туры килә торган аталган иҗтимагый яктан файдалы хезмәтләр күрсәтүен раслыйбыз.

________________________________________________________________________

___

___

(иҗтимагый яктан файдалы хезмәтнең Россия Федерациясе норматив-хокукый актлары белән билгеләнгән анық эчтәлегенә (күләм, вакыт, тәкъдим итү сыйфатык) карата таләпләргә туры килүен раслау;

___

(иҗтимагый яктан файдалы хезмәтне башкаруга җәлеп ителгән затларда (шул исәптән оешма хезсәткәрләре һәм граждандык-хокукый характердагы килешүләр буенча җәлеп ителгән хезмәткәрләрдә) тиешле квалификация (шул исәптән һөнәри белем, тиешле өлкәдә эш тәҗрибәсе) булуны раслау, шундый затларның җитәрлек санда булуы)

___

___

___

___

иҗтимагый яктан файдалы хезмәтләрне алучыларның аларны күрсәтү белән канәгать булуларын (оешма гамәлләренә (гамьсезлегенә) һәм (яки) бәяләмә бирүгә кадәрге 2 ел дәвамында суд, дәүләт контроле күзәтчелеге) һәм муниципаль күзәтчелек, башка органнар тарафыннан нигезле дип табылган иҗтимагый яктан файдалы хезмәтләр күрсәтү белән бәйле оешма карарларына карата шикаятьләр булмау) раслау

___

(коммерциячел булмаган оешма турында мәгълүматның һәркем өчен ачык булуын раслау)

___

(оешманың 2013 елның 5 апрелендә кабул ителгән «Дәүләт һәм муниципаль хаҗәтләрне тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 44-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә бәяләмә бирүгә кадәрге 2 ел дәвамында төзелгән контрактларны үтәү кысаларында хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча намуссыз хезмәт күрсәтүчеләр реестрында булмавын раслау)

Раслау документы беркетелә:

___

1. ___
2. ___
3. ___

алга таба дәвам ителә.

___

(Вазыйфа) (Имза) (Ф.И.А.и.)

«__» _______ 20__ ел

М.у. (булган очракта)

Социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар күрсәтә орган иҗтимагый яктан файдалы хезмәт күрсәтүләрнең сыйфаты билгеләнгән критерийларга туры килү-килмәве турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
2 нче кушымта
(тәкъдим ителә торган форма)

Социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешма тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый яктан файдалы хезмәт күрсәтүләрнең сыйфаты билгеләнгән критерийларга туры килү-килмәве турында бәяләмә бирүне кире кагу турында дәлилләнгән белдерү кәгазе

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы уздырган иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын бәяләү нәтиҗәләре буенча социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешма

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________
(социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешманың тулы атамасы һәм төп дәүләт теркәү номеры)

тарафыннан күрсәтелә торган түбәндәге иҗтимагый яктан файдалы хезмәт күрсәтүләрнең ___________________________________________________________;
___________________________________________________________________________;
___________________________________________________________________________.
(иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүләрнең атамалары)

сыйфаты туры килү-килмәве турында бәяләмә бирүдән баш тарта.

Әлеге иҗтимагый яктан файдалы хезмәт күрсәтүләр иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын бәяләүнең билгеләнгән критерийларына түбәндәге сәбәпләр буенча
___________________________________________________________________________;
___________________________________________________________________________;
___________________________________________________________________________.
(критерийларга туры килмәве күрсәтелә)

туры килми.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары

Социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар күрсәтә орган иҗтимагый яктан файдалы хезмәт күрсәтүләрнең сыйфаты билгеләнгән критерийларга туры килү-килмәве турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәви) кушымта

Социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый яктан файдалы хезмәт күрсәтүләрнең сыйфаты билгеләнгән критерийларга туры килү-килмәве турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган һәм аны бирүне контрольдә тотуны тормышка ашырган затларның реквизитлары

Татарстан Республикасы спорт Министрлыгы

| **Вазыйфа** | **Телефон** | **Электрон адрес** |
|---|---|---|
| Министр | (843) 222 81 02 | Vladimir.Leonov@tatar.ru |
| Министрның беренче урынбасары | (843) 222 81 03 | Halil.Shayhutdinov@tatar.ru |
| Министр урынбасары | (843) 222 81 07 | Ildar.Sadriev@tatar.ru |
| Оештыру эшләре, эш башкару һәм тикшерү бүлеге башлыгы | (843) 222 81 18 | Y.Semenova@tatar.ru |
| Массакүләм физкультура-сәламәтләндерү эше бүлеге башлыгы | (843) 222 81 45 | Dmitriy.Dorogov@tatar.ru |
| Югары казанышлар спортын үстерү бүлеге башлыгы | (843) 222 81 44 | Raif.Vafin@tatar.ru |
| Адаптив физкультура һәм студентлар спорты секторы мөдире | (843) 222 81 53 | Mihail.Marzhohov@tatar.ru |
| «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы чараларын тормышка ашыру буенча сектор мөдире | (843) 222 81 51 | Elena.Frolova@tatar.ru |
| Спорт резервын әзерләү бүлеге мөдире | (843) 222 81 72 | Natalya.Alkaeva@tatar.ru |
| Адаптив физкультура һәм студентлар спорты секторы 1 категорияле белгече | (843) 222 81 62 | Rafina.Ahmetzyanova@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
| --- | --- | --- |
| Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре буенча идарә башлыгы | (843) 264-77-84 | Guzel.Shakirova@tatar.ru |